ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.01.2026 с.Старое Дрожжаное № 15

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2025 елның 22 августындагы под-1344/25 номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы «исеме» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге)» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында»гы боерыгы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 169 (28.08.2024 № 361, от 16.09.2024 № 382, от 12.12.2024 № 504, от 15.04.2025 № 118 ред.) номерлы карары белән расланган Мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы

Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МКУ составында мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, **2 бүлекнең 1 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Муниципаль берәмлекләр мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмати-методик бүлекләре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча Урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча Урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем бирү |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 24498,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 24504,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек мөдире (җитәкчесе) урынбасары: муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча | - | - | 24598,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек; | | | |
| | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) ; | - | - | 24690,0.». |

2. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына (Хәлиуллов Г.Ф.) локаль хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карар имза салынган көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Җитәкче: Р.И. Мөхәмmәтҗанов